Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 29-о
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ 5625/14
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 3
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№ 01-02/410
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы
№ 22-п

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсы турында**

**Боерык**

2014 елның 7 октябре

Бала хокуклары турында БМО Конвенциясен популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агарту, аларның социаль-хокукый активлыгын кызыксындыру, шулай ук хокукый белемне һәм хокукый культураны арттыру өлкәсендә үсеп килүче яшь буынның позитив юнәлешле, иҗтимагый-файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалау максатларында:

1. 2014 елның 8 октябреннән 20 ноябренә кадәр «Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсын игълан итәргә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенчареспублика конкурсы (алга таба – Конкурс) турында нигезләмә

Конкурсның оештыру комитеты составы;

Конкурсның жюри составы.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил | Г.Л.Удачина |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры | Э.Н.Фаттахов |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры вазыйфаларын башкаручы | Р.М. Гарифуллин |
| Татарстан Республикасы Юстиция министры | Л.Ю.Глухова |

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы — И.Җ. Миңнеәхмәтов

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 29-о
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ 5625/14
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 3
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы № 01-02/410
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы
№ 22-п

2014 елның 7 октябре

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы (алга таба – Конкурс) Бала хокуклары турында БМО Конвенциясен популярлаштыруга, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агартуга, аларның социаль-хокукый активлыгын кызыксындыруга, шулай ук хокукый белемне һәм хокукый культураны арттыру өлкәсендә үсеп килүче яшь буынның позитив юнәлешле, иҗтимагый-файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалауга юнәлдерелә.

1.2. Конкурс агымдагы елның 8 октябреннән 20 ноябренә кадәр үткәрелә.

1.3. Конкурсны үткәрү чараларын финанслау Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы керемнәре һәм чыгымнарының җыелма сметасында каралган акчалар һәм хәйрия рәвешендә кергән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурсның төп максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максатлары:

балаларның һәм яшьләрнең актив граждан позициясен булдыру;

балалар һәм яшьләр мохитендә хокукый белем һәм традицион кыйммәтләрне пропагандалау;

халыкның хокукый белемен һәм хокукый культурасын арттыру өлкәсендә балаларның һәм яшьләрнең позитив юнәлешле, иҗтимагый файдалы иҗади эшчәнлеген пропагандалау;

медиапродуктлар булдыруда яшьләрнең иҗади күнекмәләрен камилләштерү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

хокукый культураны арттыруның актуаль мәсьәләләренә җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү;

җәмәгатьчелекнең хокукый кагыйдәләрне һәм нормаларны тотрыклы позитив кабул итүен булдыру;

хокукый күрсәтмәләрне ихтыярый үтәү һәм башкару принцибына тотрыклы позитив мөнәсәбәт формалаштыру зарурлыгына җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм кызыксындыру;

медиамәгариф һәм медиаиҗатның эчтәлеген, рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү.

## 3. Конкурсны гамәлгә куючылар һәм оештыручылар

3.1. Конкурсны гамәлгә куючылар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы.

3.2. Конкурсны оештыручылар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, «Мәктәптән тыш эш буенча республика үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф идарәләре һәм яшьләр эшләре һәм спорт идарәләре.

3.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен оештыру комитеты төзелә (алга таба – Оештыру комитеты), аңа гамәлгә куючыларның һәм оештыручыларның вәкилләре керә.

3.4. Иң яхшы эшләрне бәяләү һәм ачыклау өчен рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм әгъзалар составында 15 кешедән торган жюри төзелә.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста 6 яшьтән 30 яшькә кадәрге физик затлар, балалар һәм яшьләр оешмалары, вакытлы иҗат коллективлары катнаша ала.

Вакытлы иҗат коллективы дигәндә әлеге Нигезләмәдә Конкурста катнашу өчен 6 яшьтән 30 яшькә кадәрге физик затлардан төзелгән ихтыярый иҗат берләшмәсе аңлашыла.

4.2. Конкурс ике төркем буенча үткәрелә:

6 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар, балалар оешмалары;

18 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр, яшьләр оешмалары.

Вакытлы иҗат коллективлары тиешле төркемгә керүчеләрдән, анда катнашучыларның яшен исәпкә алып төзелә.

## 5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү шартлары

5.1. Конкурска Бала хокуклары турында БМО Конвенциясе нигезендә баланың бер яисә берничә хокукы эчтәлеген чагылдыра торган видеороликлар тәкъдим ителә.

Видеороликның жанрын катнашучылар мөстәкыйль билгели (интервью, репортаж, видеоклип, мультфильм һ.б.)

5.2. Конкурска тәкъдим ителгән видеороликлар, түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

халыкның хокукый белеме һәм хокукый культурасының югары дәрәҗәсен булдыруга һәм шуңа ярдәм итүгә юнәлгән булуы;

сюжетның кыска һәм мәгълүматка бай булуы;

видеороликның 2 минуттан артык дәвам итмәве;

видеороликның эчтәлеге Россия Федерациясе законнарына каршы килмәскә тиеш. Конкурска реклама характерындагы, шулай ук башка кешеләрнең намусын һәм хисен хурлый торган һәм Конкурс тематикасына туры килми торган видеороликлар кабул ителми.

5.3. Конкурста катнашу өчен дәгъва итүче 2014 елның 8 ноябренә кадәр теләсә кайсы электрон чыганакта (CD яисә DVD диск, флеш-туплама*)* видеоролик һәм әлеге Нигезләмә кушымтасына таянып рәсмиләштерелгән гариза, ул «Мәктәптән тыш эш буенча республика үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Хокуклар дөньясында бала» тамгасы белән, 420036, Казан шәһәре, Тимирязев ур., 8а йорт адресы буенча яисә e-mail: rcvr2014@mail.ru га җибәрелә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән вакыттан соң тапшырылган гаризалар һәм эшләр каралуга кабул ителми.

5.4.Конкурс өч этапта үткәрелә.

I этап – сайлап алу (2014 елның 8 октябреннән 8 ноябренә кадәр)

Бу этапта видеороликлар белән бергә Конкурста катнашуга гариза кабул итеп алына. Кергән эшләрне жюри карый бара һәм, әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Конкурска тәкъдим ителгән видеороликларны сайлый.

II этап – финал ( 2014 елның 9 ноябреннән 17 ноябренә кадәр).

Икенче этапта жюри Оештыру комитеты билгеләгән критерийлар нигезендә әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән яшь төркемнәре буенча иң яхшы эшләрне сайлап ала. Конкурслы сайлап алу критерийларын Оештыру комитеты 2014 елның 8 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасында Бала

хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең (rtdety.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының (mon.tatar.ru) рәсми сайтларында урнаштыра.

Бу эшләрнең авторлары Конкурсның җиңүчеләре дип танyла.

III этап – бүләкләү (2014 елның 20 ноябре).

5.5. Жюри эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Жюри утырышы әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашкан очракта хокуклы дип санала.

Жюри утырышын аның рәисе, ә ул югында – жюри рәисе урынбасары алып бара.

Җиңүчеләрне билгеләү турындагы карар утырышта катнашучыларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Аңа жюриның утырышта катнашкан барлык әгъзалары имза сала. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

## 6. Конкурска йомгак ясау

6.1. Конкурсның II этабын узган барлык катнашучылары Конкурста катнашу турында таныклык алалар.

6.2. Конкурста җиңүчеләрнең һәркайсы дипломнар һәм 20 000 (егерме мең) сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә

6.3. Конкурска видеоролик җибәреп, автор Конкурсны оештыручыларга тәкъдим ителгән материалдан, авторның исемен һичшиксез күрсәтеп, файдалану хокукы (Интернет челтәрендә, телепрограммаларда урнаштыру, иҗади проектларда катнашу, алга таба рецензияләү һәм тиражын арттыру һ.б.) бирә.

6.4. Конкурста катнашучылар яисә аларның законлы вәкилләре аларның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык бирәләр.

6.5. Конкурска тәкъдим ителгән видеороликлар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

______________________________

Кушымта

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсында катнашуга гариза**

1 Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме

2 Туу датасы, тулы яше

3. Эшнең исеме

4 Видеороликның жанры

5 Почта адресы

6 Адрес Электрон почта адресы

7 Элемтә өчен телефон (шул исәптән мобиль)

8 Мәгариф оешмасы исеме, сыйныф (булган очракта)

Имза _______________________/ /

2014 елның «_______» _________________

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсында катнашуга гариза**

1 Балалар (яшьләр) оешмасының исеме

2 Оешманы дәүләт теркәве турында таныклыкның реквизитлары

3. Эшнең исеме

4 Видеороликның жанры

5 Почта адресы

6 Адрес Электрон почта адресы

7 Элемтә өчен телефон (шул исәптән мобиль)

8 Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Җитәкченең исеме ____________/ /

2014 елның «_______»_______________

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсында катнашуга гариза**

1 Иҗат коллективының исеме (булган очракта)

2 Иҗат коллективының составы (Ф.И.А.ис., туган датасы, катнашучыларның эшләү яиса уку урыны)

3. Эшнең исеме

4 Видеороликның жанры

5 Почта адресы

6 Адрес Электрон почта адресы

7 Элемтә өчен телефон (шул исәптән мобиль)

Коллектив җитәкчесенең имзасы ____________ / /

2014 елның «_______» _____________

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 29-о
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ 5625/14
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 3
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы № 01-02/410
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы
№ 22-п

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар буенча республика конкурсының оештыру комитеты**

| | |
|---|---|
| Удачина Гүзәл Лүбис кызы | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил |
| Гыйниатуллина Светлана Владимировна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары; |
| Гарифуллин Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары; |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы Юстиция министрының беренче урынбасары |
| Сәгъдәтшин Илдар Камил улы | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы башлыгы урынбасары |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин улы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре |
| Бычкова Надежда Валентиновна | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау бүлеге |

| | |
|---|---|
| | башлыгы |
| Әсәдуллин Марсель Хатыйп улы | «Мәктәптән тыш эш буенча республика үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры |

---

Түбәндәге боерыклар белән расланды:
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 29-о
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ 5625/14
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 3
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы № 01-02/410
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы
№ 22-п

**«Хокуклар дөньясында бала» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсының оештыру комитетының жюри составы**

| | |
|---|---|
| Удачина Гүзәл Лүбис кызы | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил- жюри рәисе; |
| Гыйниатуллина Светлана Владимировна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары – жюри рәисе урынбасары; |
| Әхмәрова Ильмира Фарих кызы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының “Яшьләр, инновация һәм профилактика программаларының республика үзәге” ДБУ яшьләр белән эшләү белгече - жюри секретаре; |
| Әсәдуллин Марсель Хатыйп улы | «Мәктәптән тыш эш буенча республика үзәге» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры |
| Галимов Газинур Сабирҗан улы | Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре |
| Глухова Лариса Юрий кызы | Татарстан Республикасы Юстиция министры |
| Забегина Татьяна Вениаминовна | Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Җәләлова Анфиса Григорьевна | директор Государственного автономного образовательного учреждения среднего профессионального образования «Казан педагогика колледжы» урта һөнәри белем би-рү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе |
| Захарова Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча); |
| Сабурская Сәрия Харрис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |
| Сәгъдәтшин Илдар Камил улы | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре буенча республика агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Сәхәбетдинова Рамилә Әхмәтзакир кызы | директор творческого объединения ТРК «Яңа гасыр» ТРК«Балалар һәм яшьләр тап-шырулары» иҗат берләшмәсе директоры |
| Фазлыева Ләйла Ринат кызы | социаль мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Фәтхетдинов Салават Зәки улы | Россия Балалар фондының Татарстан бүлеге рәисе (килешү буенча) |

_______________________________________________